ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.08.2019 ел Баулы шәһәре №227

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты резерв
фонды акчаларын тоту тәртибе
нигезләмәсен раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81нче статьясы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставының 93нче статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Кушымтадагы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты резерв фонды акчаларын тоту тәртибе нигезләмәсен раслarга.

2. Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2008 елның 28 мартында кабул ителгән «Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында»гы 31нче карары (2017 елның 10 маендагы 205нче карары белән кертелгән үзгәрешләр белән), 2008 елның 26 декабрендә кабул ителгән «Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты резерв фонды акчаларын тоту тәртибе нигезләмәсен раслау хакында»гы 236нчы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасына Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акча бүлеп бирү турындагы күрсәтмәләре нигезендә, әлеге карар белән расланган нигезләмә нигезендә Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларыннан чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров